СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

*423984, ТР, Мөслим районы, Октябрь ав., Яшьләр ур., 3а й.*
Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629001152, КПП 162901001, ОГРН 1021605557863, ОКАТО 92242860001

*Октябрь авылы* « 25 » *октябрь 2019 ел.*

ТР МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ
III ЧАКЫРЫЛЫШ XLVI УТЫРЫШЫ

**КАРАР № 85**

«Җир салымы турында» 2018 елның 16 октябрендәге 71 номерлы Октябрь авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Мөслим районы прокуратурасының 29.01.2019 № 02-08-02-2019 күрсәтмәсен карау нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Октябрь авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2018 елның 16 октябрендәге 71 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:
«3. Салым ташламалары бирергә:
3.1. Индивидуаль торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, дачалар, бакча йортлары, гаражлар белән мәшгуль һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә) карата җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә физик затлар:
3.1.1. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышы инвалидларына;
3.1.2. Әфганстан Республикасында интернациональ бурычны үтәгән гражданнарга;
3.1.1.1 пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категорияләренә караган физик затларга - әлеге карарның 3.1.2 пунктчаларында санап үтелгән физик затларга ташламалар, 5000 кв.метрдан артмаган күләмдә, биләнмәгән җир кишәрлеге (өлешләр) рәвешендә бирелә.
Әлеге карарның 3.1.1 - 3.1.2 пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керүче һәм Октябрь авыл җирлеге территориясендә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган физик затларга салым ташламасы салым түләүчене сайлау буенча бер җир кишәрлеге (өлеше) өчен генә бирелә.
Торак фонды биләгән җир кишәрлегенә (өлешләргә) карата салым ташламасы салым түләүченең законнарда билгеләнгән тәртиптә даими теркәлүе

(пропискасы) булган торак фонды объекты урнашкан җир кишәрлеге (өлеш) өчен бирелә.

3.2. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100 % күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

3.2.1. оешмаларга - граждан күмүләре белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата;

3.2.2.сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестиция бизнес-проектларын гамәлгә ашыручы инвесторлар.»

б) 3,4,5,6,7 өлешләрне 4,5 , 6, 7 ,8 өлешләре дип санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм җир салымын 2020 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М. Ханнанов